| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-240 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге ПУ-944 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы һәм 2024 елның 10 маендагы 336 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар биләүче Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-243 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы белән кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт

органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2020 елның 15 августындагы ПУ-499 номерлы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2022 елның 19 августындагы ПУ-576 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-665 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 10 маендагы 336 номерлы Указы нигезендә билгеләнгән вазыйфаи окладлары (алга таба – хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары) күләмен арттырырга.

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте территориаль органы җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладлары күләмен 1,05 тапкыр индексацияләргә һәм ул 13 990 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны үтәүне тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

5. Әлеге Указ 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 03 октябрь
№ 777